**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№773**
**05.02.2021**

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 29 маендагы 2569 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктка түбәндәге эчтәлектә 3 пунктча өстәргә:

«3) субсидия алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш.»;

2) 6 пунктка түбәндәге эчтәлектә 11 пунктча өстәргә:

«11. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов